**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы**
**Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 65-13 «14» декабрь 2021 ел

Гражданнар үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыен үткәрелергә мөмкин булган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе өлешенең чикләрен билгеләү критерийларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге уставының 15.1 статьясы нигезендә;

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы

**карар итте:**

1. Үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин булган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чикләрен билгеләү критерийлары булып:

1) яшәү территориясе: күпфатирлы торак йорт подъезды; күпфатирлы торак йорт; торак йортлар төркеме; урам (урамнар); торак микрорайон; территориаль иҗтимагый үзидарә территориясе чикләре.

2) әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә кимендә 10 кеше яшәү .

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында

«Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин